ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

## Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унберенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унберенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасын раслау турында.
3. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 87-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 88-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәреш кертү хакында» 89-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясына үзгәреш кертү турында» 95-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 29 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 86-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 90-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 94-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 91-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 84-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 92-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турында доклад.

14. Транспорт өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсе мәгълүматы.

15. «Инновацион транспорт чаралары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2020 елның 20 февралендәге 297-VI ДС номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

16. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына, Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү хакында федераль законнар проектларын эшләү турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Хабаровск крае Закон чыгару Думасының мөрәҗәгате хакында.

17. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 23 статьясына үзгәреш кертү хакында» 956715-7 номерлы федераль закон проекты турында (товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр каталогын формалаштыру һәм алып бару мәсьәләсе буенча).

18. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт

системасы турында» Федераль законның 103 статьясына үзгәреш кертү хакында» 962468-7 номерлы федераль закон проекты турында (контрактлар реестрына кертелә торган мәгълүмат өлешендә).

19. «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Белгород өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

20. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан дару препаратлары үзәкләштерелгән рәвештә сатып алына торган авырулар исемлегенә арка мие мускул әгъзалары атрофиясе авыруын (СМА) кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Белгород өлкә Думасының мөрәҗәгате хакында.

21. «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 14 статьясындагы 2 өлешенең 21 пунктында күрсәтелгән, гражданнарны дәвалану өчен дару препаратлары белән тәэмин итү федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган авырулар исемлегенә арка мие мускул әгъзалары атрофиясе авыруын кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенә һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына Орел өлкә Халык депутатлары советы мөрәҗәгате хакында.

22. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга һәм «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 963678-7 номерлы федераль закон проекты турында (бакалавриат программалары һәм белгечлек программалары буенча укуга ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны билгеләнгән квота чикләрендә кабул итү хокукы өлешендә).

23. Югары белем уку-укыту программалары буенча укуга кабул иткәндә нәтиҗәләре исәпкә алына торган индивидуаль казанышлар исемлеген киңәйтү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры В.Н. Фальковка Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесе мөрәҗәгате турында.

24. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 970757-7 номерлы федераль закон проекты хакында (җирле үзидарә системасына муниципаль берәмлекнең яңа төрен кертүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү турында).

25. «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законның 49.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына

кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

26. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 957544-7 номерлы федераль закон проекты хакында (җәмәгатьчелек фикер алышуларын һәм гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен төгәлләштерү турында).

27. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 954687-7 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонтта банкның катнашуын кертү өлешендә).

28. «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 974393-7 номерлы федераль закон проекты турында (милли паркларда торак пунктлар чикләрендә җир кишәрлекләренең хокукый режимын билгеләү өлешендә).

29. «Россия Федерациясе Урман кодексының $29^1$ һәм 82 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә Депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

30. Төрлесеннән: 2020 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
урынбасары — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2020 елның 9 июле
№ 481-VI ДС